

ISSN 0868-4545

Салават күпере



Кояш елмаюы

Кояш елмайды.

Барча тереклек дөньясы хәрәкәткә килде.

Кешеләр бер-берсенә «Хәерле иртә! Хәерле көн!» диештеләр.

– Хәерле иртә! – диде сайрар кошлар да.

– Хәерле иртә! – диделәр җәнлек-җанварлар.

– Хәерле иртә! – диештеләр бөҗәкләр...

– Хәерле иртә, әнием! Хәерле иртә, әтием! – дидең Син дә.

Кадерле әбиең белән бабаңа да, өйдәге башка туганнарыңа да хәерле иртә теләргә онытмадың Син...

Дус-ишләреңә, яшьтәшләреңә һәм тагын бик күпләргә «Хәерле иртә!» – дидең Син...

...Ә бит, таң атуын белдереп, Кояш кына елмайган иде югыйсә...

Никадәр көч, кодрәт ята икән ул Елмаюда.

Әйеме?!



© "Салават күпере", 2003 ел

Кем кайда яши?

Бүре яши абзарда,
Мәче яши өенендә.
Сарык яши урманда,
Ә төлке – безнең өйдә.

Юк, болай дөрес түгел...
Сарык яши өенендә.
Төлке яши абзарда,
Ә бүре – безнең өйдә.

Юк, тагын дөрес түгел!..
Мәче яши абзарда...
Уф!.. Йәгез инде берегез
Дөрес әйтеп бирегез!

Бәхтияр ГЫЙЛЬФАНОВ.

Рәссам Алла АЙСИНА



Әкәмәт затлар



– Бүген Чытлыкайның туган көне! Бүләк әзерләргә кирәк, – диде Шаркыл дусларына.

– Әйдәгез, һәрберебез аерым бүләк әзерлик! – дип тәкъдим итте Тапкыр.



Ашамсакның бүләге күптән әзер иде инде.

– Мин Чытлыкайга «Ашаптуймаслык» дигән торт бүләк итәм! – диде ул.

– Минем... минем бүләгем әзер түгел әле, – диде Җәйлән.



Тапкыр видеокөзге бүләк итәргә булды. Уйлады, тырышты, тәки үзе ясады.

– Көзгедән үткәнне дә, киләчәкне дә күреп була! – диде ул.

– Минем бүләгем һаман әзер түгел! – диде Җәйлән.

БҮЛӘК САЙЛЫЙ

Ләбиб ЛЕРОН

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Шаркылның да бүләге, ниһаять, әзер булды.

– Сабын күбеге очырткыч түгел бу, шатлыклар очырткыч! – дип үзенең бүләгенә аңлатма бирде ул.





Дуслар Чытлыкай янына килделәр дә:

– Чытлыкай, туган көнең белән котлыйбыз! – диделәр.

Бүләкләрне берәм-берәм бирделәр.

Җәйлән, «Үзем су сибеп үстердем!» дип, салават күперен бүләк итте.

– Ә синең бүләгең кайда? – дип сорадылар дуслар Ашамсактан.

– Мин... мин... тортны... ялгыш ашап бетергәнмен... – дип авыз эчендә ботка пешереп алды Ашамсак.

Әкәмәт затлар дәррәү көләргә тотындылар.





Нәкыйп КАШТАН

Бүрекле кояш

Тышта бүген
Зыкы салкын.
Өтә битне
Ап-ак ялкын.

Туңмас өчен
Бала-чага,
Уйный әнә
Чаба-чаба.

Шыгырдаулы
Бүген капка,
Әйтеп кала:
– Озак чапма!

Бияләйсез
Куллар пешә –
Очкан кошлар
Туңып төшә.

Сарыкларга
Куна песнәк,
Йөнтәс йонда
Җылы эзләп.

Чыпчыкларның
Җылы йорты –
Сыерларның
Бәсле сырты.

Агачлар да
Энҗе бәстә,
Бәс кигәннәр
Өшемәскә.

Атларга ак
Сакал үскән.
Кара ат та
Ап-ак төстән.

Хәтта Кояш
Туңа микән –
Колакчынлы
Бүрек кигән.



Минем чанам

Нишләсемне
Әйбәт беләм:
Йөгереп мин
Тауга менәм.

Тау башында
Тора Кояш,
Тау төшәргә
Кыяр-кыймас.

Иркен минем
Тимер чана,
Сыя хәтта
Кояш аңа.

Икәү бергә
Җай юк куркыр –
Син чанама,
Кояш, утыр!


Рәссам Илдар НӘФИЕВ







Фирдүс ХӘЙБУЛОВ



Альбина ӘХМӘТШИНА



Руслан ХӘЙБУЛОВ



Чулпан ҖАМАЛЕТДИНОВА




Фирүзә БУРКЕЕВА

Кадерле дус!

Синең игътибарга яшьтәшләреңнең рәсемнәрен тәкъдим итәбез. Кызыгып китеп, бәлкем, үзең дә рәсем ясарсың әле.

Ошбу битттәге сурәтләрне Кукмарадагы сәнгать мәктәбенә йөрүче балалар (җитәкчеләре – Рада һәм Расих Сәләховлар), ә сул битттәге рәсемнәрне исә Буа районы Иске Суксу мәктәбе укучылары (җитәкче – Әлбинә Кәримова) җибәрде.



Илшат ҖИҺАНШИН




Илдар МИНҺАҖЕВ



Алмаз ГАБДРАХМАНОВ



Алмаз ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ



А.ГАРИФУЛЛИН. 9 яшь

Зиннур ХӨСНИЯР

Алмачуар әкияте

(Ахыры. Башы журналыбызның 2002 нче елның 8-9,10,11-12 нче һәм быелның 1 нче санында.)

Ул орышның ничек булганын һич кенә дә сурәтләп бетереп булмастыр. Язып аңлатырга уйласаң, каләмнең карасы җитмәс иде. Сүз белән сөйләп бирергә теләсәң, мөгаен, телдә сүзләр бетәр иде. Бик нык торды алмачуарлар, үз-үзләрен бер дә аямадылар. Шулчак элек читтәрәк йөргән атлар да, акылларына килеп, көрәшкә кушылдылар. Тик соң иде шул инде! Һай, соң иде!!! Кабаннар бик күп еллар буе бары бер ата кабанга буйсынып яшәделәр. Шуңа күрә күп тә һәм көчле дә иде алар. Ә алмачуарларның һәр көтүе үзен көчле дип уйлады. Бер-берсенә баш бирергә теләмәделәр...

Алмачуар иле җиңелде. Ләкин алай дип кенә дә әйтеп булмый иде әле. Шактый еллар атлар кабаннарны пыр туздырып килделәр. Кемнең генә буйсынасы килсен инде. Җитмәсә ул дуңгызлар адым саен алмачуарларның саф сулы чишмәләрен пычратып, тәмле печәнле көтүлекләрен таптап, мыскыл итеп йөрделәр. Ни әйтсәң дә дуңгыз дуңгыз шул инде...

Әүвәл кабаннар: «Бергә яши башласак, сез, алмачуарлар, рәхәт күрерсез дип, әллә ниткән вәгъдәләр биргәннәр иде. Кайда вәгъдә калсын ди! Берсен дә үтәмәделәр. Теге сатлыкҗан Галишаһ алмачуар да рәхәт күрмәде, аны бик тиз авызлыкладылар. Аңа шул кирәк инде, әлбәттә! Үз туганнарыңны сатып йөрсәң шулай була ул, мәхлүк җан! Хан була, имеш! Тотты пычагымны!.. Әйе. Ачуым килгәнгә генә әйтәм инде моны! Сатлыкҗан барыбер беркайчан рәхәт күрмәячәк инде анысы...


Алмачуар атларның күзләре элек ялкын кебек иде. Хәзер алай түгел инде. Һай, алай түгел шул инде хәзер...

Алмачуар атларның күзләрендә моң бар...

Рәссам Фәрит ***МУЛЛАХМӘТ***







– Син сорасаң, күп бирәләр,
Йәле, мәм-мәм сора! – ди...
Әни! Әти! Нишлим инде,
Колагымны бора бит?!

Казан.

– Берәм-берәм сала торгач,
Шыплап тулды дәү чиләк...
Ашап кем дә үсә аны,
Эшләп үсәргә кирәк!

Апас, Сатламыш.



Конкурс!
Мин бит бу?!





– Киносын да, мультигын да...
Карадым мин барын да!
Көне буе телевизор
Карый торгач, арылды...

Апас, Болын Балыкчы.




– Сезгә әйтеп тормас идем...
Әйтмичә һич калалмыйм:
Борынымның тишегеннән
Бармагымны алалмыйм!

Казан.



– Кигән идем аякларга
Әтиемнең башмагын...
Тыпыр-тыпыр-тыпырдап,
Мин бии дә башладым!

Башкортостан, Балтач.




Кадерле дуслар!

Журналның урта битен иплəп кенə алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөклəгез дə килеп чыккан кисəклəрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын — уртасын ике урыннан төплəп куегыз.

©«Салават күпере» китапханәсе.

Рәссам **Диләрә Нәүрузова**



Ак күбәләк

Ап-ак күлмәген киеп,
Шаярып, уйнап-көлеп,
Динә суга йөгерә –
Әй үзе соң өлгер дә! –
Кайтып җитә тиз генә,
Су сибә җитез генә
Бакчадагы гөлләргә –
Аларны бик сөйгәнгә.
Сыйпап үтә таҗларын:
– Үсегез, – ди, – җаннарым!..
Йөри гөлләр тирәләп,
Әйтерсең, Ак күбәләк!





Аллаһыма Рәхмәт төшкере:
Һәр күңелдә – Салават күпере!..
Балкышыннан күзләр чагыла,
Җылы арта төшә җанымда...

Шаһинур Мостафин



Кинәш

Агачларга, коймаларга
Исемен яза Самат:
«Искә төшерерләр, – ди ул, –
Шул язганнарга карап!..»

Үзен әллә кемгә санап,
Исемен уя һаман...
Бер карт, туктап, әйтте аңа:
«Шәп эш түгел бу, балам!»

Ярдәм ит син өлкәннәргә –
Тик йөргәнче урамда.
Әйтер күпләр: «Менә уңган –
Булыша бит зурларга!

Исемеңне язмасаң да,
Халык йөртер гел зурлап, –
Язганнарың югалырлар,
Эшең калыр бик озак!..»

Сыбызгы борын


Галигә зират яныннан
Үтәргә туры килә.
Бик курыкканга, йөрәге:
«Чыгам, чыгам!!!» – дип тибә...

Җитмәсә, сызгыра кемдер,
Арттан куалар кебек!
Өенә кайтып егыла
«Аһ!» килеп тә, «ваһ!» килеп...

Тик монда да сызгырулар
Тукталмый да туктамый...
Шунда гына Гали-«батыр»
Ялгышканлыгын аңлый.

Борыны сызгыра икән ич!
Еласынмы, көлсенме?!
...Куркаклык ул – иң зур хурлык! –
Харап итә кешене...





Бака кашыгы

Күгәргәнче су коенып
Морат кайтты өенә:
– Менә, ни таптык елгадан,
Карале! – дип сөенә.
Йөгереп килде сеңлекәше
Шул табышны күрергә:
– Нәрсә ул?
– Бака кашыгы!..
Җәмиләнең йөзенә
Борчу чыкты:
– Ул кашыгын
Онытып калдыргандыр.
Илтеп бирик – кашыксыз ул
Ашый алмый торгандыр!..

Хат языша җәнлекләр...

Кыш Бабайның тылсымыннан
Ап-ак булган җирнең өсте –
Беркем кулы кагылмаган,
Язылмаган дәфтәр төсле!

Куян кызы чабып үтә
Шул «дәфтәр»гә сүзләр язып...
Озакламый Эт малае
Укыр аны – эздән барып!..



Кызганды

Таң белән чыктылар юлга –
Иртән җим сорый балык.
Үттеләр елга буена
Болын аша юл ярып.
Нур баскан саен, чәчәкләр
Сына да, чык коела...
Абыйсы артыннан бераз
Карап баргач тын гына,
Әйтте аннан нәни Наил,
Тәмам сабырын җуеп:
– Ник елатасың аларны
Үзең зур була торып!



Суык-рәссам

Суык-рәссам
Бар нәрсәгә
Оста икән! –
Тәрәзәгә
Нинди матур
Чигү чиккән...
Арыш-бодай
Сурәтләре
Аңа төшкән:
Гүя, уңыш
Мул буласын
Хәбәр иткән!



Мөҗәһит Әхмәтҗанов шигыре.
Земфира Шәяхмәтова көе.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Җырлап яшәр чагыбыз



Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлап яшәр чагыбыз.
Нинди матур, нинди гүзәл
Безнең туган ягыбыз.

Йөрәкләрдә җыр яңарсын,
Канат куйсын, яшәртсен.
Җырлап туярга язмасын,
Яшәсен җыр, яшәсен.

Безнең җырга сез дә шулай
Кушылып кул чабыгыз.
Йөрәкләрне җилкендереп,
Җырлап яшәр чагыбыз.



Дини хикәятләр

Адәм

Аллаһ беренче кешене – Адәмне – балчыктан бар итте, аңа җан өрде. Шуннан соң Аллаһ үзенең фәрештәләренә әйтте: «Адәмне Күк белән таныштырыгыз, аңа искиткеч гүзәллекләрне күрсәтегез!» – диде.

Күктә очып әйләнгәндә Адәмнең башына зиннәтле ташлар белән бизәлгән алтын таҗ, бармагына исә затлы балдак кидерделәр. Алтын таҗның ялт-йолт итүеннән хәтта кояш белән айның нурлары да күренмәссизелмәс булды.

Аллаһ фәрманы белән Адәмгә барча фәрештәләр баш иде. Бары тик Иблис кенә баш имәде.


– Мин Адәмнән әйбәтрәк. Аллаһ Адәмне балчыктан, ә мине уттан бар итте! – диде ул.

Әлеге тәкәбберлеге өчен Иблис оҗмахтан куылды.

Шуннан соң Аллаһ барча җир-су хайваннарын, кошларны вә бөҗәкләрне Җирдән фәрештәләр янына китерде дә аларның исемнәрен әйтергә кушты.

Адәмнән кала, бер генә фәрештә дә җан ияләренең исемнәрен әйтә алмады.

Рәссам Булат ГЫЙЛЬВАНОВ








Әбиеңә дә сөйлә

Казанны кәҗәләр коткара

Төнлә галлар римлылар качып яткан Капитолий калкулыгына һөҗүм итә. Сакчылар аларны күрми, этләр дә сизми кала. Казлар гына ишетәләр һәм, бик нык каңгылдап, Рим сугышчыларын уяталар. Шулай итеп, Римны казлар коткара. Бу хакта синең йә ишеткәнең, йә укыганың бардыр. Без дә «Сыбызгы» журналында (№ 3, 2002 ел) язып чыктык. Ә менә Казанны кәҗәләр коткарганын беләсең микән?..

Бу хакта язучы Равил Вәлиев Казан тарихы турындагы хикәятләрендә бәян итә. 1656 елда Казанда куркыныч чир тарала. Йөзләрчә, меңнәрчә кеше кырыла. Хәлбуки, безнең бабайлар афәт килгәндә, хәвеф-хәтәр янаганда, корбан чалып, Аллаһы Тәгаләгә ялвара торган булганнар. Бу юлы корбанга сарык та, сыер да түгел, ә кәҗәләр сайлап алына. Корбан чалу Казансуның аръягында, Кремльгә каршы ярындагы аулак тугайда башкарыла. Кешеләрнең ялварулары, догалары Ходайга барып ирешә, күрәсең. Чир чигенә. Халык җиңел сулап куя. Еллар узу белән кәҗәләр корбан булган изге урында бистә үсеп чыга. Аны «Кәҗә бистәсе» дип атап йөртәләр.





Фидель ХӘСӘНОВ коллажы.
Александр ЭШКИНИН фотосурәтләре кулланылды.



Минем уенчыкларым

Курчак

Табышмак әйтәм, җавабын тап:

Минем белән уйныйлар,
Кулларыннан куймыйлар.

Иркәлиләр, сөяләр,
«Йокла, иркәм», – дияләр...

Рәссам Светлана ПРИВИНА



Йə, табышмакның җавабы ни булыр?

Əлбəттə, курчак. Əгəр син кыз бала икəнсең, ул сиңа бигрəк тə таныш, якын. Шулай бит?!

Синең үзеңнең нинди курчакларың бар? Син аларны яратасыңмы? Аларның исемнəре нинди?

Минем курчакларым (исемнəрен яз):

____

_______________________.

Һəдиянең ике курчагы бар. Берсе Мəдинə, икенчесе Лəйлə исемле. Туган көнендə тагын бер курчак бүлəк иттелəр Һəдиягə. «Курчагыма нинди исем кушыйм икəн», – дип бик озак уйлады. Ниһаять, яраткан ике курчагының исемнəреннəн (МƏ-ДИ-НƏ һəм ЛƏЙ-ЛƏ) берəр иҗекне алды да яңа курчагына исем ясады. Уйлап кара əле, Һəдиянең курчагы ни исемле?

Əз-мəз тарих

Бик-бик күп еллар, хəтта гасырлар элек, кешелəр мəгарəлəрдə – тау куышларында яшəгəн заманда ук балалар курчаклы уйнаганнар икəн. Археологларның эзлəнү-казынулары шуны күрсəтə.

Мəҗүсилəр – Айга, Кояшка, Йолдызларга табынып яшəүчелəр – үлгəн кешенең җаны



шул курчакларга күчə дип уйлаганнар.

Мөселманнарда кеше сурəте ясау тыелган, шуңа күрə аларның тукмак-курчакларының йөзлəре булмаган.

Курчакларны төрле нəрсəдəн эшлəгəннəр. Ярлы халык балалары салам, сөяк, балчык, агач курчаклар белəн уйнаган.

Россиядə исə XVII-XIX гасырларда курчакларны күбесенчə чүпрəктəн теккəннəр.

Сəхифəне **Илсөяр ГАРИПОВА** əзерлəде.


Табышмак әйтәм – җавабын тап!



Уйнаклап сикерә-сикерә,
Тәгәрәпме тәгәри.
Тисәләр дә еламый,
Коткаруны сорамый.



Эче буш – тавышы калын,
Үзе дәшми – сөйләшми.
Әгәр берне чиертсәң,
Тавышлана, дөберди.



Ишегалдында туып үскән,
Борыннарын өшеткән.
Яз кояшы елмайгач,
Гөрләвек булып аккан.

Нинди хәл инде бу:
Үзе әле бик нәни;
Тик бер дә еламый
Һәм мәми сорамый.
Яткызсаң – ята,
Торгызсаң – утыра.

Җилдән узып чаба ул,
Сикертмәгә әләксә –
Мин аннан узып чабам.
Һәм ак карга мәтәләм.

Җир өстеннән баралмый,
Тирән карда бата ул.
Бозда исә башкача,
Бер таймыйча чаба ул.

Җаваплар (көзге ярдәмендә укы):
Туп. Чана шуу. Тимерчак. Барабан. Кар бабай. Курчак.

Салават күпере

2-3(155-156) — 2003
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Фәрит Якупов рәсемнәре.


Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.


Производствога бирелде 25.02.2003 ел.
Басарга кул куелды 25.02.2003 ел.
Кәгазь форматы 60x100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 12000 данә. Заказ Я-78.
Бәясе килешү буенча.



Табышмаклар

Кеше дисәң, кеше түгел,
Җәнлекнең дә ише түгел.
Көне-төне эшли ул,
Ару-талу белми ул.
Зифа буйлыдыр үзе,
Маңгаенда – өч күзе.
(Светофор)

Өч аяклы, мөгезле,
Утыртып йөри безне.
(Велосипед)



Тәрәзәле, ишекле,
Кечкенә өй шикелле.
Һәрчак юлдан ул йөри,
Аяклары... тәгәри.
(Автобус)

Сания СӘЙФУЛЛИНА.
Казан.



Җавапларны көзге ярдәмендә укы.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

